ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 6 өлешендә «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү федераль корпорациясе» акционер җәмгыятенә» сүзләреннән соң «(алга таба – кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү корпорациясе)» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяда:

а) 1 өлештә «Вәкаләтле орган, җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтә торган вәкаләтле орган, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Федераль законның $14^1$ статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән физик затларга ярдәм күрсәткән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтә торган вәкаләтле орган, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар ярдәм алучы мондый физик затларга карата әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән реестрларга белешмәләрне Федераль законда күрсәтелгән тәртиптә кертәләр. Бу реестрларга әлеге статьяның 2 өлешендәге 1, 4 – 8 пунктларында каралган белешмәләр белән берлектә мондый физик затның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының

исеме кертелә, шулай ук тиешле ярдәм күрсәтү турында карар кабул ителгән датага мондый физик затның индивидуаль эшкуар булмавы һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллануы күрсәтелә.»;

в) 3 өлештә «вәкаләтле орган» сүзләреннән соң «, башка Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен өстәргә;

3) 9 статьяның 3 өлешендә «финанс ярдәме» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан башкасы каралмаган булса,» сүзләрен өстәргә;

4) 12 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «финанс» сүзеннән соң «, шул исәптән гарантия,» сүзләрен өстәргә;

5) 14 статьяда:

а) исеменә «Финанс» сүзеннән соң «, шул исәптән гарантия,» сүзләрен өстәргә;

б) беренче абзацта «Кече» сүзен «1. Кече» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм (яисә) кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга гарантия ярдәмен күрсәтү илкүләм гарантия системасында катнашучылар тарафыннан Федераль законның 17[1] статьясында каралган йөкләмәләр буенча поручительлекне тәэмин итү һәм (яисә) бәйсез гарантияләр бирү юлы белән гамәлгә ашырыла, илкүләм гарантия системасында катнашучыларга кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү корпорациясе, «Кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү Россия банкы» акционер җәмгыяте, шулай ук законнарда үзләренә һәм эшчәнлекләренә карата билгеләнгән таләпләргә туры килә торган кредитлаштыруга булышу фондлары (гарантия фондлары, поручительлек фондлары) керә.»;

6) 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4[1] өлеш өстәргә:

«4[1]. Индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар эшчәнлеген үстерү өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән әлеге статьяның 3 өлешендәге 1, 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә мәгълүмат системаларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм итү буенча рәсми сайтларда урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Законның индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга әлеге Законда каралган ярдәмне

күрсәтүгә кагылышлы нигезләмәләре «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән эксперимент уздыру срогы дәвамында кулланыла.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 13 ноябрь
№ 66-ТРЗ